**СОВЕТ СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 8(84378)4-12-91
e-mail:stolb.la@tatar.ru

**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СТОЛБИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 8(84378)4-12-91
e-mail:stolb.la@tatar.ru

**2024елның «29» марты** **55 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге советының «Җир салымы турында» 2021 елның 18 октябрендәге 23/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге Советы нигезендә КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге советының «Җир салымы турында» 2021 елның 18 октябрендәге 23/1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 1 2 пунктның 2.2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле «д» абзацы өстәргә:

“ 20 млрд.сумнан ким булмаган инвестицияләр күләмен, гомуми мәйданы 500 мең кв. метрдан артык һәм резидентлар белән берлектә 15 меңнән артык урын булдыруны күздә тоткан логистик технопарк булдыру буенча масштаблы инвестицион проектны гамәлгә ашыру кысаларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 3 пункты һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 33.3 статьясы нигезендә юридик затларга арендага бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,05%, (төзелеш чорын да кертеп, унбиш елга).»

2. Әлеге карарның нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Столбище**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.Ю. Романова**